**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**БОЕРЫК**

2019 нчы елның «09» апреленнән № 71

Төп гомуми белем бирү программаларын үзләштергән укучыларга дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү максатыннан, 29 декабрь, 2012 ел, № 273-ФЗ «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 59 маддәсенең 13 бүлеге белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 23.03.2019 ел, № 604-р боерыгын үтәү йөзеннән:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегенә:

2019 елда төп дәүләт имтиханы үткәрүне тәэмин итәргә;

2019 елда «Татар теле» һәм «Татар әдәбияты» фәннәреннән төп гомуми белем бирү программалары буенча, «Татар теле» һәм «Татар әдәбияты» фәннәрен өйрәнгән һәм әлеге фәннәрдән имтихан алган укучылар өчен бердәм республика имтиханын үткәрергә.

2. Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының Яңа Чишмә районы буенча бүлегенә Яңа Чишмә мәгариф бүлеге белән берлектә имтихан үткәрү пункты янындагы территориядә җәмәгать тәртибен саклауда һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдә кирәкле ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

3. Төп дәүләт имтиханын һәм бердәм республика имтиханын оештыру һәм үткәрү өчен җирле бюджеттан акча бүлеп бирүне күздә тотарга.

4. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Фәсахов Р.Р.**